# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Иске Пукшинер торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

3 ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Иске Пукшинер торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «2024 елда гражданнарның үзара салымын Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Иске Пукшинер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә (I төркем инвалидлар өчен; үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнар; балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналар (законлы вәкилләр); Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контракт хезмәте үтүче хәрби хезмәткә чакырылучыларга, мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 90% күләмендә ташлама каралган).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Иске Пукшинер авылында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында http://baltasi.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Заляев